Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Олы Болгаер авыл җирлеге Советы

КАРАРЫ

2019 елның 13 декабре № 123

Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Олы Болгаер авыл җирлеге Генераль планына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Су басу зоналары чикләрен билгеләү турында" 2014 елның 18 апрелендәге 360 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Олы Болгаер авыл җирлеге Советы карар итә:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Олы Болгаер авыл җирлеге Советының 2019 елның 9 апрелендәге 97 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Олы Болгаер авыл җирлеге Генераль планына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а)икенче өлешнең 8 бүлегендәге 2 пунктының 13 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 елның 18 апрелендәге 360 номерлы РФ Хөкүмәте карары белән расланган су басу зоналары чикләрен билгеләү кагыйдәләре нигезендә, су басу зоналары Россия Федерациясе субъектының җирле үзидарә органнары белән берлектә әзерләнгән башкарма хакимият органының су басу зоналары чикләрен билгеләү турында тәкъдимнәре (алга таба-тәкъдимнәр), әлеге зоналар чикләренең урнашу урынының график тасвирламасыннан гыйбарәт булган әлеге зоналар чикләре турында белешмәләр, күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрын алып бару өчен билгеләнгән координаталар системасында мондый зоналарның характердагы чикләре координаталары исемлеге буенча су ресурслары федераль агентлыгы (аның территориаль органнары) тарафыннан билгеләнә яисә үзгәртелә. Су басу зоналары чикләрен график тасвирлау рәвеше, шулай ук территориядән файдалануның аерым шартлары булган зона чикләре координаталарын, су басу зоналары чикләре турында белешмәләр булган электрон документ форматын билгеләү төгәллегенә карата таләпләр Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы тарафыннан билгеләнә. Су басу зоналарын билгеләү яисә үзгәртү турындагы карар су ресурслары федераль агентлыгы (аның территориаль органнары) акты белән рәсмиләштерелә.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә үзем тотам.

Олы Болгаер авыл җирлеге башлыгы З.И. Сәйфуллина